КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 11 сентябрь г.Казань № 860

Татарстан Республикасында территорияне комплекслы үстерү турындагы карарларны тормышка ашыруга вәкаләтле юридик затны билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасында территорияләрне комплекслы үстерү проектларын тормышка ашыруны тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциягә карамаган оешмасын Татарстан Республикасында территорияне комплексы үстерү турындагы карарларны тормышка ашыруга вәкаләтле юридик зат итеп билгеләргә.

2. «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциягә карамаган оешмасына 30 көн эчендә, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән берлектә, Татарстан Республикасында территорияләрне комплексы үстерү проектларын тормышка ашыруда катнашучы затларның үзара хезмәттәшлеге регламентын эшләүне тәкъдим итәргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә торуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин